Кәүсәрия
ШАФИКОВА

Рәфис
МӨХӘММӘТДИН

*

# ИКЕ АККОШ

ШИГЫРЬЛӘР

·МӘГЪРИФӘТ·
УФА·1995

Башкортстан Татар телле язучылар союзы тәкъдиме нигезендә республика Социаль яклау министрлыгының матди ярдәме белән нәшер ителә
Төзүчесе, мөхәррире һәм кереш сүз авторы – Фәрит Габдрәхим

Кәүсәрия Шафикова, Рәфис Мөхәммәтдин. Ике аккош.– Уфа, «Мәгърифәт», 1995 ел, 120 бит.
ISBN 5-900166-04-X

Яңавыл районында яшәп иҗат иткән һәм бердәй авыр язмышка дучар ителгән танылган әдипләр, Башкортстан Татар телле язучылар берлеге әгъзалары Кәүсәрия Шафикова белән Рәфис Мөхәммәтдиннең бер тышлык астында чыгучы бу китабына нигездә лирик шигырьләре туплап бирелде. Алар иҗатына тыйнак, тыгыз һәм киеренке шигъри аһәң, дөньяга сокланып карауның хиссияти башлангычы белән образлы фикерләүдәге үсә барган зәвыкның тыгыз төйнәлеше хас. Җыентыкка Кәүсәрия талантының тагын да бер ягын гәүдәләндергән эшләре – графика ысулында төшерелгән сурәтләре дә урнаштырылды.

ISBN 5-900166-04-X © Мәгърифәт, 1995 ел.

# РУХИ КАҺАРМАНЛЫК

Мин бүген Кәүсәрия Шафикова белән Рәфис Мөхәммәтдиннең шигырьләренә, алар иҗатының кайбер үзенчәлекләренә кыскача күзәтү ясарга телим.

Ә ни өчен нәкъ менә икесенә? Моның сәбәбе, бер карaганда, бик өстә ята. Кәүсәрия дә, Рәфис тә бер төбәктән – Яңавыл районыннан. Ләкин эш анда гына түгел. Барыннан да элек, аларны шәхес буларак та, иҗатчы буларак та уртак язмышлары үзара якынайта. Ачы язмыш сабый чакларыннан ук аларны йомшак бәбкә үләне өстеннән ялан тәпи йөгерә-йөгерә, тәкмәч ата-ата уйнаудан, авыл буасында балык кебек чума-чума йөзүдән, иптәшләре белән әбәкле уйный-уйный урманга барудан, анда үз куллары белән җиләк тәлгәшләре өзеп алудан, буй җиткергәч егетләр белән гармунга кушылып җырлый-җырлый урам ураудан, яисә көянтә-чиләк белән бөгелә-сыгыла чишмәдән су ташудан мәхрүм иткән. Мәрхәмәтсез язмыш сабый чакларыннан ук аларны урын-җиргә салып бәйләп куйган. Ләкин батыр рухлыларны, матур күңеллеләрне берниди көч тә тезләндерә, буйсындыра алмый икән. Моңа кадәр татар әдәбияты дөньясында ике иҗат каһарманы – Гакыйль Сәгыйров белән Фәнис Яруллин бар иде. Шушы каһарманнар сафына Кәүсәрия белән Рәфис өстәлде.

Мин Кәүсәрия Шафикованың шигырьләре, нәсерләре белән күптәннән танышмын. Алай гына да түгл, «Кызыл таң» редакциясендә эшләгәндә кулыма килеп кергән һәр кульязмасын да диярлек бастырып чыгарырга тырыштым. Ә Рәфис Мөхәммәтдин шигырьләре белән беренче тапкыр моннан берничә ел элек кенә таныштым. Кем икәнен дә, нинди язмышлы кеш икәнен дә белми идем, әлбәттә. Әмма шигырьләре шундук игътибарымны җәлеп иттеләр.

Миңа һаман да бер сорау тынгылык бирми. Менә шушы күп нәрсәләрдән мәхрүм ителгән затлар ни өчен шигырь язалар, иң мөһиме, ничек кешеләр күңеленә хуш килерлек шигырь яза алалар? Һәм уйлана торгач, үзем өчен шундый нәтиҗә ясадым. Көчле ихтыяр. Башкалардан ким буласы килмәү. Кешеләр сине кимсетеп карамасын. Матурлыкка чиксез гашыйк булу. Кешеләргә изгелек кылырга омтылу. Шушы теләк-омтылышлар Кәүсәрия белән Рәфисне шигърият доньясына тарткан да инде, минемчә. Мондый затлар башка кешеләр ишетмәгәннәрне дә ишетәләр, башка кешеләр күрмәгәннәрне дә күрәләр. Аларның бәгырьләре дә әнә шул ишеткән-күргәннәре тудырган кичерешләрдән гыйбарәт. Һәм аларның шигырьләрендәге сүзләр дә гади сүзләр түгел. Бәгырь пәрәләре ул сүзләр. «Көчле бул» дигән шигырендә К. Шафикова нәкъ әнә шул хакта әйтә: «Кайгысын да, шатлыгын да шул җаным кабул итә. Шокер, әле барысын да күз яшьләрем һәм җырларым итәргә көчем җитә!» Әлбәттә, Рәфис тә үзенең сулкылдап торган бәгырен шигырь итә. Һәм моны ул үзенчә әйтеп бирә: «...каләмемне манып язам йөрәк каныма». («Шигырь язам»).

Мин Рәфис һәм Кәүсәриянең язмыш уртаклыгыннан тыш, иҗат уртаклыгын да күрәм. Икесенең дә шигырьләре артык ярсу да булмаган, шул ук вакытта бигүк сүлпән дә булмаган моң агымын хәтерләтә. Моң агымы... Анда нинди генә авазлар, нинди генә төсләр юк! Шушы моң агымында берничә аваз, берничә бизәк аеруча нык күзгә ташлана. Шуларның берсе – туган җиргә мәхәббәт. Адәм рәтле һәр шагыйрьнең иҗат җирлеге була. Бу ике шагыйрьнең беренче иҗат җирлеге (сызык астенә алып

әйтәм: «беренче») – Яңавыл тобәге. Географик атама гына түгел бу. «Туган җиргә җитми» дигән шигырендә Рәфис: «Туган авылым, сине сагынып кайтам, торган җирләр яхшы булса да»,– дип, туган авылның күңелгә кадерле, газиз булуын раслый. Монда, әлбәттә, поэтик ачыш юк. Ләкин бу юллар икенче бер мөһим нәрсә турында сөйли. Рәфис туган авылына кайтмый да, аннан каядыр китми дә, гел шунда яши. Әмма ул шигырьдә үз хисләре белән генә мавыкмый, дөньяга башкалар күзе белән дә карый белә. Башкалар күңелен дә аңлый алу – шагыйрь өчен мөһим сыйфат. Кәүсәрия дә үзенең авыр язмышыннан, газаплы тойгыларыннан өстен булу сәләтенә ия. Кәүсәрия шигырьләренең дә беренче җирлеге – туган як. Шагыйрә «Алтын» шигырендә: «Син алтын!»– дип бүген игенчегә әйтергәдер әле, могаен!»– ди. Ә игенче бу фикерне тагы да үстерә төшә: «Юк, дөресен әйтер менә хәзер иген үстерүче ялкын-ир. Шулай диар: «Ә алтынмы, алтын – безне сөендергән Туган җир!» Күрүебезчә, шигырьдәге герой табигатьтән, бу очракта туган җирдән өстен түгел, бәлки аның җанлы бер кисәге. Һәм бу дөрес тә. «Кайтып әйлән» дигән җырында Кәүсәрия Яңавылга, Бүә буйларына чакыра, уңган якташларына дан җырлый.

Аларның моң агымында колакка нык чалынган тагын бер аваз, күзгә ташланган тагын бер бизәк – изге күңелле кешеләргә мәхәббәт. Тормышта бик күп нәрсәләрдән мәхрүм булсалар да, Кәүсәрия белән Рәфискә дә сөю хисе ят түгел. Бер шигырендә Рәфис ире үлгән хатын фаҗигасен тасвирлый: «Җирне тырный-тырный елый, дәрья аның күз яше». Шул чак үз тиңе чыгар әле, дип авыл халкы фараз кыла. «Беренчесе булмый шул ул, хет меңгә барып кара». Менә шундый юллар белән тәмамлана өч строфалы гына бу шигырь. Әгәр бу сүзләрне автор әйтсә, акыл сату кебегрәк яңгырар иде. Ошбу сүзләрне шагыйрь ачысын-төчесен бик күп татыган икенче бер тол хатыннан әйттерә, һәм шигырьнең тәэсир көче бермә-бер артып китә. Шуны да әйтергә кирәк, гашыйкларга гына хас сөю уты Рәфис белән Кәүсәрия йөрәгендә дә яна! Серне чишкән өчен мине гаепләмәсләр дип уйлыйм: саф, чын сөю хисләре бәйли алар күңелен... Кәүсәриягә багышлаган «Кояшым бул» дигән шигырендә Рәфис: «Тавышыңны

бер көн ишетмәсәм, югалткандай булам көнемне. Мәңге сүнмәс яз кояшы бул син, шау чәчәк ит күңел гөлемне!»— ди. Кәүсәриянең дә наз тулы җаны нур чәчә, аның да ихлас тойгылар бөркелгән шигырьләре байтак. Татлы сөю хисләренең кадерен белгән пар йөрәк алдында безгә сокланып баш ияргә генә кала.

Бу икәүнең әниләрен яратулары да һәркемгә үрнәк булырлык. Кәүсәриянең «Бишегемдә чагында да...» дип башланган исемсез шигырен генә алыйк. Нәкъ менә үз әние турында, нәкъ менә үзе турында ул. Дистә еллар буе әнисе аны сабый бала урынына караган. Һәм менә озын-озак еллар дәвамында кара язмыш кочагында бәргәләнгән кызының хәлен аз гына булса да җиңеләйтү өчен кырыкмаса кырык тапкыр төнге йокыларын бүлгән Ана мәңгегә күзләрен йома. «Ах! Коточкыч, үлем килде, Әнкәй, синсез калдым». «Көн дә урынга ятканда рәсемеңә багам. Әйтәсең күк: «Авыртынсаң, эндәш миңа, балам!» «Мин эндәшәм сиңа, сагынып, тик пышылдап гелән, җаннан суырылып чыккан шигырь теле белән, Әнкәй!» Тел шартлатып сокланырлык метафораларга корылмаган бу шигырь, ә хәбәр сөйләүгә корылган. Әмма мондагы һәр сүз, әлеге дә баягы, бәгырьне тураклап ясалган.

Мин югарыда беренче иҗат җирлеге турында әйткән идем. Ә бит милли шагыйрьнең, әгәр ул чынлап та милли шагыйрь булса, икенче иҗат җирлеге, ягъни төп җирлеге була. Ул милли җирлектән гыйбарәт.

Һәр халыкның буыннан-буынга күчә килгән, меңмең еллар дәвамында барлыкка килгән рухи дөньясы була. Ул башка халыкларныкына охшаган да, охшамаган да. Татар рухы да шулай. Аның таллары да татарча сөйләшә, чишмәләре дә татарча челтери, кызлары да татарча ояла. Милләттәшләребез кайгыны да, шатлыкны да үзенчә кабул итә, үзенчә кичерә. Бу инде милли психологиягә барып тоташа. Мәсәлән, татар халкы белән башкорт халкының рухи дөньясы бик якын, хәтта күпләр аны аермый да. Охшаш яклар күп булса да, барыбер алар арасында аерма да бар. Барыбер алар икесе ике халык. Аермалык, үзенчәлек иҗатта да, димәк, шигърияттә дә чагылмый кал . ı н.

Шигърияттә татар милли җирлеге, барыннан да элек, татар

халык иҗатына барып тоташа. Моннан тыш шигъриятебез борынгы язма әдәбиятыбыз традицияләренә, Кол Галинең үлемсез «Кыйссаи Йосыф»ына, аннан соңгы бай әдәби ядкарьләребезгә, мәҗүси һәм дини йола, гореф-гадәтләребезгә, фәлсәфәбезгә бәйләнгән.

Нәтиҗә. Башкортстанда да татар шигърияте бар. Димәк, аны тудыручылар да бар. Алар рәтенә мин Кәүсәрия Шафикова белән Рәфис Мөхәммәтдинне дә кертер идем. Әнә бит Кәүсәрия үзенең «Иманым» дигән шигырендә ничек ди: «Татарча уйлыйм, татарча сөйлим, татарча җырлыйм! Татарча соям, татарча көләм, татарча елыйм...» Шул рәвешле, ул татар рухлы булуын раслый. Кәүсәрия белән Рәфиснең шигырьләре дә татар рухлылар. Алар кулланган поэтик чараларның татар халык иҗатына, язма әдәби традицияләргә тыгыз бәйләнгән булуын исбатларга мөмкин. Ләкин мин монда гыйльми тикшеренү алып бармыйм. Анысы галимнәр эше.

Сүземне йомгаклап шуны гына әйтәм. Кәүсәрия Шафикова белән Рәфис Мөхәммәтдиненең шигырьләрен бер тышлык эчендә китап итеп чыгару дөрес булыр. Бу ике моң агымы бер-берсеннән читләшми, киресенчә, бер-берсен баета гына. Кәүсәриянең кызларча йомшак, нәфис тавышына Рәфиснең ир-егетләрчә ышанычлы, нык тавышы өстәлеп, менә дигән дуэт барлыкка килә. Кәүсәрия сәләтенең тагын бер ягы ачылып килә, ул рәсемнәр дә төшерә икән. Алар китапка үзенчәлекле бизәк-ямь өсти. Арада «Ике аккош» рәсеме дә бар. Китапның «Ике аккош» дип исемләнүе символик мәгънәгә ия. Аккош — пакьлек, наз, тугрылык билгесе. «Аккош»ларның икесенә дә илһамлы иҗат телик.

*Фәрит ГАБДРӘХИМ*

*11 апрель, 1995.*

Кәүсәрия
ШАФИКОВА

# КӨННӘРЕМ ГӨЛЛӘР КЕБЕК







## Үзем турында

Мин, Шафикова Кәүсәрия Фидан кызы, Башкортстанның Яңавыл районы Исәнбай авылында, 1948 елның 9 ноябрендә тугакмын. Гаиләдә беренче бала. Әткәм-әнкәмнең зур шатлыклары да, гомерлек кайгы-хәсрәтләре дә булдым. Бала чагымнан авырыйм, мине аякка бастырырга медицинаның көче җитмәде, 1 нче группа инвалидмын, әткәм һәм мәрхүм әнкәем урынына миңа ярдәм кулын сузган Зиния апа тәрбиясендә яшим. Кеше ярдәменнән башка бер генә көн дә яшәү мөмкин булмаса да, авыр язмышны каргап, елап яшәмим. Кеше елмайса, тормышта матурлык арта, мин моны яхшы аңлыйм.

Шигырьләрем, нәсерләрем 1970 елдан башлап Башкортстан, Татарстан гәзит-журналларында, күмәк җыентыкларда әледән-әле дөнья күрә. Радио һәм телевидение музыкаль тапшыруларында минем сүзләргә язылган җырлар да яңгырый.

Әйтәсе сүзеңне шигъри телдә, башкалар йөрәгенә барып җитәрлек итеп әйтә алу – ул зур бәхеттер! Укытучылар өйгә килеп укырга-язарга өйрәтсәләр, тормыш мине көчле җил-давылларга бирешмичә яшәргә өйрәтте. Үземне көчле итеп тоям, мине яшәүгә булган мәхәббәтем чиксез көчле итә!

*Автор.*

# Кызлар җыры

Чылтыр-чылтыр чишмәләрнең
Сафлыгы бар.
Күктә йөзгән болытларның
Аклыгы бар.
Күчкән аңа чәчәкләрнең
Матурлыгы.
Тулган аңа ай-кояшның
Якты нуры.
Бар үз моңы, бар сагышы,
Бар шатлыгы,
Иртәләрен искән җилнең
Йомшаклыгы.
Дулкыннары килеп какса,
Җанга җылы.
И син гүзәл, мәңге тынмас
Кызлар җыры!

# Иманым

Татарча уйлыйм,
Татарча сөйлим,
Татарча җырлыйм.
Татарча сөям,
Татарча көләм,
Татарча елыйм.
Татарлыгымнан
Ходай үзе дә
Аера алмас.
Гонаһлы санап,
Җанымны тәмуг
Утына салмас.
Иманлы итеп,
Бер сүзле итеп,
Үзе җан өргән.
Мәхәббәтемне
Мәңгелек итеп
Ялкынга төргән.
Әнкәм сөтенең
Тамчысы саен
Аклык алганмын.
Шуңа да инде
Бербөтен татар
Булып калганмын.
Татарча елыйм!
Татарча көләм!



*

Кагылам да күңелләрнең
Өзгәлимен бар кылын.
Мин моңлы җыр, мин күз яше,
Җан көйдерә ялкыным.
Мин юлларга чакырып дәшәм,
Якынайтам еракны.
Әллә ничә меңгә телэм
Йодрык кадәр йөрәкне.
Коем белән, денем белән
Һәркемгә дә таныш мин.
Имәннәргә тиңнәрне дә
Тал-тирәктәй бөгелдергән
Сагыну мин, сагыш мин.

# Чишмә

Күптән татып караган юк
Чишмә суының тәмен.
Чишмәләргә бару бетте,
Авыл җуйды бер ямен.
Торбалардан килә сулар,
Чишмә юлы онытылды.
Каз-үләнле сукмакларга
Кычыткан, әрем тулды.
Чишмә үзе исән әле,
Тирә-ягы тал гына.
Суның тәме элеккедер,
Чиләк тутырып ал гына!
Көянтәле авыл кызын
Чишмә һаман көтәдер.
Минутлары, сәгатьләре
Сагыш белән үтәдер.
Чишмәләргә бару бетте,
Тормыш элекке түгел.
Чишмә ялгыз калыр микән?
Юк, чишмәне ялгыз итмәс
Сагына белгән күңел!

## Әнкәйне юксыну

Чәчкәнең зәңгәрен сагынып,
Кырларга ашкынам көн саен.
Күзләрең зәңгәре мөлдерәп
Чәчәккә күчкәндер, могаен!
Төн җитсә, йолдызлар кабына,
Сибелә зәп-зәңгәр нурлары.
Күзләрең түгел шул, зәп-зәңгәр
Йолдызлар кабына нибары!
Төн җитсә, йолдызлар кабына,
Тын гына тирбәлә күк чәчәк!
Күзләрең мәңгегә йомылган,–
Зәңгәр төс үзәкне өзәчәк!

## Кошлар кайтыр!..

Көз китә дә кошлар, язын кайта,
Кайта да ул кора оясын.
Нигә Ходай китүләрсез генә
Яратмады икән дөньясын!
Еракларга сәфәр чыгып киткән
Якыныңны көтеп аласың.
Әллә нигә төрле китүләр, әй,
Көтә икән адәм баласын.
Салкын гүре тартып ала аны,
Чаралар юк алып калырлык!
Яз килгәндә үксеп калганнарга
Бирсен берүк Ходай сабырлык!

## Төймәле кыз

Миләшкәем, ялт-ялкынланып
Утырасың бакча түрендә.
Җепкә тезгән кызыл җимешләрең
Төшләремә керә бүген дә.
Сигез генә яшьлек чагым иде,
Берәм-берәм өзеп тәлгәштән,
Үземә дә, сеңелемә дә дип,
Төймә тездем кызыл миләштән.
Хәтеремдә һаман шул матур көз,
Ул кып-кызыл миләш бүген дә!
Төймәле кыз кайгы-хәсрәт белми,
Көлә-көлә яши күңелдә!

## Күршедә малайлар үсә...

Бер яшь солдат ут чәчәргә
Кулына мылтык алган.
Нигә түгелә күз яше?
Нигә түгелә ал кан?
...Юк, үзе теләп атмый ул,
Кушалар: «Үтер!»— диләр.
Табутта кайта егетләр,
Табутта бөркет ирләр.
Күршедә малайлар үсә,
Күрсәтер Ходай ниләр!

# Заман җиргә күктән төшми

Сагындырып куя бүген
Көлеп яшәгән заман.
Тыңлап торам да, кешенең
Зар-елавы бик яман.
Тормышны сүгә, дау кылә,
Ямьсезләнә ни өчен?
Күкрәк сугып яши иде,
Кая куйган ул көчен?
Мохтаҗлыклар, бозыклыклар
Аның йөрәген иги.
Нигә әле «Барсына да
Үзем гаепле!»— дими?
Коточкыч күрү кешене
Баскычның түбәнендә.
Ул бит әле югарыга
Менеп җитәр хәлендә!
Эше барның ашы да бар,
Ник зарлана ул һаман?
Әйтерме килеп бер аңга:
«Түзик! Тозәтик! Үзебез
Койсезләндергән заман!»



❄

Яфракларны агачыннан
Җилләр чеметеп өзә.
Һәм аларны сагыш итеп,
Күңел-җепләргә тезә.
Тирәкләрнең яшел чагы
Минем яшьлегем булган.
Инде энә бар дөньяма
Мөлдерәпләр моң тулган.
Әй! Әйләнеп килгән язга
Күңел кабат алданыр.
Өзелер дә ялганыр ул,
Өзелер дә ялганыр.

## Авыр көн

Тәрәзәләр шадраланган,
Сибәли көзге яңгыр.
Яратмыйм мондый көннәрне,
Йөрәккә бигрәк авыр.
«Корвалол» тамчыларыннан
Беraз хәл табам кебек.
Яшисем килми уфтанып,
Яшисем килә көлеп.
Түтәлдәге гөл түгел мин,
Көз җитте дип шиңәргә.
Бөтен авыр көннәрне дә
Кирәк миңа җиңәргә.
Көрәш мәйданына чыктым,
Егылмый егасым бар.
Әле яңа җырлар белән
Язларга чыгасым бар!

## Кояшлы буран

Торып калдым хисләр буранында,
Ап-ак икән хисләр бураны.
Сине эзләп шул ак бураннарда
Бу дөньяны ничә урадым.
Мин таптыммы, синме, булганбыз ич
Бер үк юлда, бер үк буранда.
Юлыбызны мәңге югалтмабыз,
Буранnарда кояш булганда!

## Күрше апага

Күрше апа, үстер гөлләремне,
Синең өйдә чәчәк атсын алар.
Юлга чыгам, әле мин кайтканчы,
Көннәр генә түгел, үтәр айлар.
Бозга каткан тәрәз төпләрендә
Калдырасым килми гөлләремне.
Синдә калсын алар, көтсен мине,
Якынайтып кайтыр көннәремне.
Минем гөлләр синдә чәчәк атар,
Берсе атар алны, берсе акны.
Сагыну итеп ал гөлләре белән
Алып китәм җанда Туган якны.

## Мин татар

Мин татар, татар кызы мин,
Шул бөтен матурлыгым!
Татарлар елмаеп үлгән,
Татарлар елмаеп яши,
Шул минем батырлыгым!
Мин татар, татар кызы мин,
Моңдашым минем Тукай!
Җырларымда түгәрәк ай,
Кояш, нечкә билле таллар,
Зәңгәр чәчәкле тугай!
«Мин татар!»– дип, тамырлардан
Акса да кайнар каным,
Рәхмәтемне сиңа әйтәм,
Җырлап яшәр илһам биргән
Җирем – Башкортстаным!

## Алтын

Яфраклары сары булган өчен,
Алтын димиләрдер көз аен.
Уңган җиләк-җимешләре белән
Алтын диләр аны, могаен.
Басу тулып үскән игеннәре
Алтын итә көзне ел саен.
«Син алтын!»– дип бүген игенчегә
Әйтергәдер әле, могаен!
Юк, дөресен әйтер менә хәзер
Иген үстерүче ялкын-ир.
Шулай дияр: «Ә, алтыны, алтын –
Безне сөендергән Туган җир!»

❄

Үсмер чакка кайтыр идем,
Бер гашыйк булыр өчен.
Тоясым килә тагын бер
Андагы хисләр көчен.
Елыйсым килә тагын бер
Татлы яшьләрем белән.
Гашыйклар яше, чык булып,
Гөлләргә куна, беләм.
Янар идем, ялкынымны
Якты йолдызлар итеп.
Юк, мин сөюдән туймадым,
Шушы яшемә җитеп.
Гашыйклар таңы якты ул,
Кичләре аның зәңгәр.
Үсмер чагымда итеп күр,
Синең күзләргә багарга
Оялып торсам әгәр.

# Мин ышана идем кешеләргә

Тик бер генә ялган, шул бер ялган
Ышанычны тәмам югалтты.
«Дус булырбыз!» диеп кул бирде дә
Йөрәгемә төбәп ук атты.
«Ышанмам!»– дип антлар итәргәме?
И Ходаем, бирче, бир түзем!
Антым шушы: Кеше йөрәгенә
Ук атучы булмам мин үзем!

❄

Кайтыр юлда кошларның да
Канатлары таладыр.
Басып сайрар тирәгенә
Кайталмыйча каладыр.
И Ходаем, юлларыма
Куя күрмә киртәләр.
Авылыма кайтмый калсам,
Җырсыз туар иртәләр.
Үләң кояр, гөлләр шиңәр,
Безнең тамыр бер җирдә.
Яңгырларда минем сою,
Назларым искән җилдә.
Кайталмасам, сою мине
Сагыш булып саргайтыр.
Кайталмаммы, юк, кайтырмын,
Кайтыр, кошлар да кайтыр!

## Күз яше

Күрсәтмәдем сине беркемгә дә,
Иреннәрем генә тешләдем.
Килгән кайгыларны борып салдым,
Кочле идем, әллә нишләдем!
Нишләдем мин бүген, җиңеләмме?
Юк, горурлык исән күңелдә.
Син, күз яшем, әйлән таң чыгына,
Үләннәргә сибелеп җемелдә!

❄

Укытучы дия идем сине, тормыш,
Укытучы гына түгел икәнсең син.
Укытучы сөгенергә өйрәтми бит,
Син өйрәттең, ярсып-ярсып сөгенәм мин.

Бу доньяда сөгенмичә яшәрсең, бар,
Иң беренче сөгеп ташлыйм явызлыкны.
Тәмле телем белән әллә иркәлимме
Кара кигән кайгыларны, ялгызлыкны?!

Шагыйрәгә сөгенү һич килешми дип
Әйткәннәр бар... Мин күргәнне күрмәгән ул.
Ул җылына гына әле учакларда,
Бәгырьләрне откән утка кермәгән ул.

Юк әлегә шигырьләрдә сүгенгәнем,
Туры килсә кулланырмын аңысын да.
Кем гаепләр, юк, табылмас андый кеше,
Син тормыштан алып яшим барысын да.

## Син көткәндә

Күккә баксам – син ак болыт,
Җиргә баксам – син чәчәк.
Беләм, мине сагынуларым
Синең янга илтәчәк!
Син көтәсең, син көткәнгә,
Сагынып яшимендер.
Ялкын тулы хисләремне
Тамчы да яшермимдер.
Күккә баксам син тулган ай,
Җиргә баксам – син сою!
Син көткәндә бәхет бит ул
Сөеп утларда кою!

## Сабантуйлар җитте

Сабантуйлар җиткән саен
Күңелне сагыш сара.
Кулъяулыклар чиккән чакны
Онытын яшәп кара!
Матур итеп чигә идем,
Оста иде кулларым.
Бүләкләдем сабантуйның
Батыр дигән улларын.
Кулъяулыкка чигә идем
Чәчәкләрнең алларын.
Әле һаман җанда саклыйм
Шулчакның ялкыннарын.
Куллар гына инә тотмый,
Табарсың ни чарасын?!
Тулым-тулым, аллы-гөлле
Җепләрем дә бар да соң!
Булмый инде, яшь кызларга
Калдырам бу һөнәрне.
Алар чиксен кулъяулыкка
Яшьлектәге тосен жуймас,
Шиңә белмәс гөлләрне.

❄

Мәхәббәт дип сөенеп яшимен,
Мәхәббәт дип үксеп елыймын
Мәхәббәт дип колэм-елмаям,
Мәхәббәт дип өзелеп җырлыймын.
Мәхәббәттә күрәм бар ямьне,
Мәхәббәтне яклап көрәшәм.
Мәхәббәт дип утлар йотамын,
Мәхәббәт дип ярсыйм, көйләшәм,
Мәхәббәтем өчен яхшылык
Кылырмын мин хәтта яманга.
Тик бер генә нәрсә, бер генә:
Мәхәббәт дип бармам ялганга!



❄

Бәхетсезлек нигә килде,
Сынаргамы көчемне?
Югалттым шул газизләрдән
Газиз булган кешемне!
Инде сынган булыр идем,
Кайгыларым бик авыр.
Әнкәемнең соңгы сүзе:
«Балакаем, бул сабыр.
Бул сабыр!»
Бер күбәләк уйның голдә,
Ул-җан, диләр, ышанам.
Чәчәк аткан гөлләремне
Күрергә кайткан анам!

## Җырлап яшә

*Җырчы Наил Шәймәрдановка*

Кайткан кошлар киткән әйдә,
Аларга шулай язган.
Син китмә, аерылмасын
Күңелләр ямьле яздан.
Синең тавыш кайгыларның
Юлларын киссен әле.
Давыллары тынып торсын,
Җил генә иссен әле.
Яшәү шатлыгын җуйганнар
Елмайсын әле кабат.

Күзләренең яшен сөртсен,
Иңеңдә тойсын канат.
Җырла әле, бер түгелсен
Сагыш белән тулганнар.
Яшьлек дәрте белән янсын
Туксанын тутырганнар.
Моңың белән яшьләребез
Күңеленә юллар яр.
Күңелләрнең нечкә кылын
Мең чыңлатыр җырлар бар.
Җырлап яшә, көзне, кышны
Язлардай матур ит син.
Бүә буе талларында
Тирбәлгән былбыл бит син!

❄

Кеше хәлен кеше белсен иде,
Үз башына төшми белми шул.
Кайгы күрмәгәннәр алдында син
Башкасыңны күтәр, горур бул!
Күзләреңнең яшен күрмәсеннәр,
Сиңа гына аның ачысы.
Бөгелеп төшмә әле, авыр, диеп,
Кайгыларның җиңел кайсысы?!
Хәлләремне беркем аңламады,
Көчле санап күзгә бактылар.
Түзә белүемне үзләренә
Яшәү көче итеп таптылар!

❄

Чәч агара, теш коела,
Картлык, син киләсеңме?
Күңелнең синнән көчлерәк
Икәнен беләсеңме?
Кил әйдә, кил, түремнән уз,
Тик кон күрсәтмәс күңел.
«Мин әле яшь, матур!» дияр,
Сүзен бирәчәк түгел!
Ул үзенә гашыйк итәр,
Чибәр бит, чәчәк кебек.
Гомер буе күңел шулай
Яшәр картлыктан көлеп.

## Карлы иртә

Сибелә кар энҗеләре,
Урам тулган аклыкка.
Иртә белән карлар ява,
Юрыйк берүк шатлыкка.
Кайгылардан кара коймик,
Кер кунмасын сафлыкка.
Яңа карның яктылыгы
Юл күрсәтсен хаклыкка.
Яшик әле ак доньяда,
Аклардан да ак булып,
Кара таплар калмас бездән,
Чәчелмәсәк вак булып,
Яши белсәк сак булып.

Яуган карлар уйларымны
Гел шулай матур итә.
Башкалар да нәкъ шулайдыр,
Зур рәхмәт, карлы иртә.

## Кайтып әйләп

*(җыр)*

Оныттыңмы әллә бөтенләй үк
Унҗидедә, унсигездә чакны?
Еллар үткән, юллар ерак, димә,
Бер күрергә кайт син Туган якны.

Кушымта:
Яңавыл ул, безнең Яңавыл,
Ул кичәге түгел, яңа ул.

Барган саен Бүә буйларына
Искә алам чәчәк кебек чакны.
Танымаслар инде, димә әле,
Бер күрергә кайт син Туган якны.

Кушымта.

Еракларда гомер кичерсәң дә,
Кайтып әйләп, күр бүгенге чакны.
Якташларның кайнар мәхәббәте,
Алтын кулы бизи Туган якны.

Кушымта.

Күз яшьсез дә үксеп-үксеп
Елаган чак бар.
Бар, кайгысы бар дип белми,
Яшәгән чаклар.
Әле алай, әле болай
Итә бу тормыш.
Берүзеңә мең төрле төс,
Мең төрле тавыш.
Көчле бул син, яшәү-көрәш,
Гел шатлык килми.
Яшисе килмәгәндә дә
Үләсе килми.

## Сынар өчен

Өшемиме яфраклары агачларның,
Ачылырга торган чәчәк бөреләре?
Яшел хәтфә үләннәре урамымның
Туңмаганмы, һәммәсе дә тереләрме?
Көтмәгәндә йөрәгемне өшеттерде
Ап-ак карга төренгән бу май иртәсе.
Язмыш төсле икәнсең лә, әй, табигать.
Соң, синнән дә көчле булыш, ни әйтәсең?!
Тукта, бар бит, бар андый көч: җан ачуы,
Яшәү көче өзә язмыш богауларын.
Әй, табигать, тормыш кебек сыныйсың син,
Әйе, сынап карар өчен бу вакытта
Яуган карың, яуган бозың, кырауларың...

# Сер сөйләдем

Сер сөйләдем
Искән җилгә,
Үскән гөлгә,
Ак болытка,
Янган утка,
Очкан кошка,
Якын дуска.
Җил – тыначак,
Гөл – сулачак,
Ут – сүнәчәк,
Кош – үләчәк,
Явар болыт
Яңгыр булып,
Сер калачак
Онытылып.
Дус-дус булып
Калыр әле.
Серне саклый
Алыр әле.

# Тал икән

Үзендә таудай көч
Бар икән.
Бөгелде, сынмады,
Тал икән.
Көчлене имәнгә тиңлиләр,
Имәннәр нык була, диләр дә.
Яр буе таллары булу да
Бик җиткән авырлык килгәндә.
Җил-давыл котыра, дулкыннар
Үксиләр кочаклап ярларны.
Мин күрдем коточкыч бу мәлдә
Бирешми тибрәлгән талларны.
Бөгелде, сынмады,
Тал икән.

# Иң матур җыр

Тыпылдап тамчы тамды,
Күңелләргә моң салды.
Бу – язгы моң. Яз килде,
Наз өләште яз, көлде.
Бар җир калды сафланып,
Чүп-чар акты су белән.
Нуры белән кояшның
Битен юды яшь үлән.
Күңел очты талпынып,
Моң түгелде, җыр туды.
Иң матур җыр кырларда,
Кырда – хезмәт, кырда – яз,
Җир йөзенә ямь тулды.

# Бүген җилләр талгын исте

Ак болытны мендәр итеп,
Җил йоклый төшләр күреп.
Төшендә дә йоридер ул,
Каен чукларын үреп.
Үтәдер ул элгән керне
Җилфердәтеп чак кына.
Тирбәтәдер чәчәкләрне
Кочып алып сак кына.
Су буена йөгереп төшеп
Дулкыннарны куадыр.
Бөгелгән тал бөдрәләрен
Агым суда юадыр.
Кояш батты, ай калыкты,
Таң белән җил уяныр.
Бүген нинди җил исәр, дип,
Дөнья күргән уйланыр.

❄

Ай түгәрәк икән,
Зәңгәр икән йолдыз.
Әллә нишләп шуны
Әле белде бер кыз.

Бу таңнарның төсе
Чылап алсу икән.
Кар сулары кебек,
Хисләр ярсу икән.
Кызның керфекләре
Чыклы үләнмени,
Ләкин сагышны ул
Белми әле, белми.
Йөрәк яна, кем соң
Салган аны кузга?
Тәүге мәхәббәте
Килгән икән кызга.

## Кыр казлары

Кыр казлары очып үтте,
Парсыз алар, санадым.
«Кая булды берегез?»— дип
Үзләреннән сорадым.
Бер каз моңсу тавыш бирде:
«Киткән идек алты пар,
Berебезне, минем дусны,
Кичә атып алдылар».
Нәрсә булды бу доньяга?
Күзләр күрмәс булдымы,
Яз киттеме җир йөзеннән,
Бар матурлык сулдымы?
Кыр казлары очып үтте
Унбер бөртек барысы.
Инде минә йөрәгемдә
Шул казларның кайгысы.

# Гаилә

Ир малайны киендерә,
Хатын кызның чәчен тарый.
И сабыйлык, тормыштагы
Чынбарлыкны белми, ярый.
«Әни!»– дип кыз хатынкайның
Күзләренә соеп карый.
«Балакаем!»– ди хатын да,
Ефәк чәчне тарый-тарый.
Кошчыкларның икесе дә
Чит оядан килде монда.
Бәхетсезлек очрап тора
Яшәешнең зур юлында.
Мәхәббәт бар, балалар юк,
Ходай шулай кушкан инде.
Ире әйтте: «Бала алыйк!»
Җан таләбе кочле – җиңде.
Әнә алар уйный-колә,
Бер гонаһсыз ике сабый.
Әй, бу донья, бәндәләрен
I инди генә утка салмый!
Чит куенда җылы тапты
Ике бала, ике ятим.
Ташлап киткән әниләрен,
Исәннәр, дип ничек әйтим.
Җансыз алар, бу доньяны
Пычраталар, кабахәтләр.
Үз баласын беркемгә дә
Ташлап китми хәтта этләр.
Ә хатыннар, кара, нишли,
Ходай итмәс бер җәзасыз!

Тик баланың күңеле дә
Булмыйдыр шул бер ярасыз!
Еллар үткәч тормыш үзе
Барысын да аңлатачак.
Ә бүген ул-шат күбәләк,
Нинди әйбәт син, бала чак!
...Ир малайны киендерә,
Хатын кызның чәчен тарый.
Бу сабыйлар күңеле белән
Кояш җиргә көлеп карый!

❄

*Гыйлемдар Рамазановның*
*якты истәлегенә*

– Баланыгыз бигрәк уңган,
Өзәргә ләкин иртә!
– Бәлешенә чакырырмын,
Тәмләнер чагы җитә!
– Яратам балан бәлешен,
Онытa күрмә, чакыр!
– Онытмам!
Ике дус шулай
Сөйләште соңгы тапкыр.
Ризыкка язмады балан,
Дусның берсе юк инде.
Мең үлемне җиңгән иде,
Бу юлы үлем җиңде.
Бәлеш пешәр. Бүген җимеш,
Йөрәкнең кан тамчысы!
Күчте инде күз яшенә
Баланның бар ачысы!

❄

– Агачлар, ничек сынмыйсыз
Җилләрдә, давылларда?
– Сынмыйбыз, үрнәк булырдай
Көчле кешеләр барда!
– Кеше ничек чыдый микән,
Яна утларга кереп?
– Кеше ул яшәр коч таба,
Яшел яфраклар күреп.

## Кайттым

Төкерим лә шәһәренә,
Үз итмәгәч үз итмим.
Сиңа кайттым әле, авыл,
Кайттым, тиз генә китмим.
Сиңа кайттым әле, авыл,
Синдә яшәү ямьлерәк.
Җылырак чыккан кояш та,
Пешкән аш та тәмлерәк.
Бераз үпкәлим язмышка,
Туган җирдән аерды.
Күңелкәем канатларын
Канаткачны каерды.
Ярый әле юллар ачык,
Сагынгач кайта алам.
Тагын кайттым, бер кош булып,
Җәй буена, Туган җирем –
Тал-бишегемдә калам.

# Көчле бул

Җаным бар, җанымны саклыйм,
Җил тидермим мин аңа.
Әнкәй әйтте: «Юкка гына
Тудырмадым дөньяга,
Син көчле бул, бу тормыштан
Җаныңа алма кара!»
Җаным чиста, эреп-эреп
Сызласа да мең яра,
Кайгысын да, шатлыгын да
Шул җаным кабул итә.
Шөкер, әле барысын да
Күз яшьләрем һәм җырларым
Итәргә көчем җитә!

❄

Ашыктырып дәшә юллар,
Бөтенләйгә китү түгел.
Тик нигәдер гомерлеккә
Хушлашкандай эрни күңел.
Тәгәрәп лә төшә яшьләр,
Төбәлгән дә күзләргә күз.
«Сау бул инде, сау бул!»— дибез,
Әйтеп булмый башка бер сүз.
Киләчәктән бер тавыш бар:
«Очрашулар кояшлы бит,
Әй, гашыйклар, түзегез, түз!»

# Күзләреңә бактым

*(җыр)*

Күзләремә тулма берүк,
Яшь ачылары булып.
Там әле, там учларыма
Яз тамчылары булып.
Үксетмә мине, әрнетмә,
Йөрәк ярасы булып.
Тирбәл күңелем язларының
Умырзаясы булып.
Хисләремдә тойыйм әле
Язгы ташкыннар көчен.
Синең күзләреңә бактым,
Бәхетле булыр өчен.

❄

Әллә ничә шигырь язылмый,
Әллә инде язып бетердем.
Бик күп яздым, утым-ялкыным
Кыш аенда язлар китерде.
Шигырь итеп яздым сөюне,
Шигырь белән туды көннәрем!
Ник язылмый, кырау суктымы
Шигъриятнең назлы гөлләрен?!
Йөрәгемнең тавышын ишетәм,
Ярсып-ярсып типкән бер мәле:
«Һич борчылма әле, язылыр,
Юк, мәхәббәт исән чагында
Шигърияткә үлем юк әле!»

## Чәчәк өши

Кар болыты, май аенда
Бик ямьсез күренәсең.
Син бит әле күзен ачкан
Чәчәккә үреләсең.
Сабый-чәчәк өшеп елый,
Туңып калганнары бар.
Язмыш ачысыннан көчле
Булып калганнары бар!
Май аенда яуган карлар,–
Минем күргәннәрем ул.
Былбыллар килде талларга,
Болыт, яңгыр гына бул!
Болыт, җылы яңгыр бул!

❄

Кайнар яшен түгә күзләр,
Күрәләр: «Нигә?» диләр.
Юаталар: «Йә, тынычлан,
Уйлама әллә ниләр.
Бар да әйбәт булыр әле,
Бар да табар үз җаен!»
Йөрәк елый, күрүче юк,
Беркем күрмәс, могаен!
Ела, йөрәк, күрмәсеннәр,
Кермәсеннәр хәлеңә.
Тик җырыңнан гына тынма,
Көч бар синдә әлегә!

## Яшел яфрак

Яшел яфрак, бүген сине
Җилләр үбә — наз гына.
Их, гел шулай, менә шулай
Булсын иде яз гына.
Яшел яфрак, әле сине
Җылы яңгыр чылатыр.
Салкыннары җаннарыңны
Тетрәндереп елатыр.
Яшел ярфак, әле синең
Сап-сары буласың бар.
Җырларыма сагыш булып,
Мөлдерәп туласың бар!

❄

Врач булсам, мин дәвалар идем
Тәннәрдәге бөтен яраларны.
Мин шагыйрә, йөрәк сүзем белән
Агартасым килә караларны.
Күңелләрнең эрни җәрәхәте,
Мин шагыйрә, ничек читтә калыйм?!
Илһам чишмәсеннән сулар алып,
Дәваланам үзем һәм дәвалыйм!

## Ялгызларга

Кара әле, агачларда
Оялар!
Бу кошлар, дим, бик бәхетле
Бит алар!
Ишетерсең нәни кошлар
Тавышын.
Кем ишетер синең йөрәк
Кагышын?
Кабат-кабат ояларга
Карарсың.
Сагышланып ялгызлыгың
Каргарсың.
Бәлки әле соң түгелдер,
Җан-тәнең
Җылытырга үз учагың
Ягарсың!

❄

Бишегемдә чагымда да
Уятканмын сине.
Татлы йокыларың бүлеп,
Тирбәткәнсең мине.

Уяттым сине кырык ел,
Тонгэ ничэ тапкыр!
Әйтә идең: «Авыртынсаң,
Кирәк булсам, чакыр!»
Әнкәй!– диеп эндәшүгә,
Урыныңнан тордың,
Әйләндердең мине уңга,
Уңнан сулга бордың.
Хәлләреңне алды минем
Язмыш авырлыгы.
Пешләр идем, әгәр сынса
Синең сабырлыгың!
Кырык елның юлын үттек,
Давылларда калдык.
Түзә белгән очен генә
Үрләр яулый алдык!
Ах! Коточкыч, үлем килде,
Әнкәй, синсез калдым.
Синсез калдым, мәңгелеккә
Син йокыга талдың.
Кон дә урынга ятканда
Рәсемеңә багам.
Әйтәсең күк: «Авыртынсаң,
Эндәш миңа, балам!»
Юк, эндәшмим сиңа, Әнкәй,
Торалмавың беләм.
Җиде яттан ярдәм сорап,
Тон тынлыгын бүләм.
Мин эндәшәм сиңа, сагынып,
Тик пышылдап гелән
Җаннан суырылып чыккан
Шигырь теле белән: Әнкәй!

## Аерылмыйк

*(җыр)*

Телмә лә бәгырьне, җанымны,
Моң-сагыш утында яндырма.
Өзелгән чәчәктәй сулырмын,
Син мине ятларга калдырма.
Син мине ятларга калдырма,
Коязын сүндермә көннәрнең.
Җил булып кисмә син сабагын
Чәчәккә күмелгән юлларнең.
Син мине ятларга калдырма,
Гомергә үзәкне өзәрсең.
Үзең дә гомерең буена
Сагынып җылымны эзләрсең!

## Кунакка кайткан берәүгә

Сиңа, авылдашым, дип,
Ничек эндәшим?!
Урысчалатып әйтәсең:
«Городта яшим.

Только погостить приехал,
Тиздән уеду.
Авылда тудым и үстем,
Приезжать буду.
Шумный город ждет меня,
Авылда калмыйм.
Да, скучаю, но бөтенләй,
Юк, кайта алмыйм!»
Телсез булып кайткансың бит,
Нишләдең, бәндәм?
Үзең тоймыйсыңдыр, син бит
Кызганыч хәлдә!
Анаң да, авыл да сиңа
Ятсынып бага:
И бала!.. Бала!..

❄

Бераү сөйли күргәннәрен,
Сөйли күз яше белән.
Яраларын яңартуы
Бик авыр аңа, беләм.
Зарлана бераү чиреннән,
Төнен керфек какмаган.
Ничә төрле дару ашап,
Бер файдасын тапмаган.
Нишлим, тыңлыйм тыныч кына,
Бүлдермим мин аларны.
Миңа карап җиңсеннәр, дим,
Чирләрне, кайгыларны!

## Кеше көчле

Бар көннәрнең кояшлысы, болытлысы,
Күңелне дә шул көннәргә тиңләп була.
Кайгы килсә күкләреңне болыт каплый,
Күңел бакчаңдагы гөлләр елап сула.
Болытларны җилләр куа, тормышыңнан
Кайгыларың-хәсрәтләрең куар өчен,
Син җилләргә әйлән, юк, җил көче җитмәс,
Давылларга әйләндер син күкрәк көчең.
Җанда бар да терелергә генә тора,
Сулды дигәч гөлләр әле чәчәк атар.
Кеше көчле! Син көчеңне сынап карап,
Көзләр җитте дигәч язны кире кайтар!

# Күзләремә карап көл

*(җыр)*

Өзгән гөлләр бүләк итмә,
Өзгән гөлләр тиз сула.
Сулган гөлләр күргән саен
Күзләремә яшь тула.
Кулың белән гөлләр өзмә,
Үзәгемне өзәрсең.
Өзгәләнгән чакларымда
Кайгыларда йөзәрсең.
Өзгән гөлләр бүләк итмә,
Күзләремә карап көл.
Мәхәббәт – ул үзе чәчәк!
Мәхәббәт – ул үзе гөл!

## Шомырт – мәхәббәт агачы

Әйт әле, шомырт агачы,
Син шуны әйтеп кара,
Чәчәкләрең ап-ак синең,
Җимешең нигә кара?
Яктылык өсти дөньяга
Тәлгәшләрең аклыгы.
Анда керсез күңел төсе,
Анда сөю сафлыгы.
Ак тәңкәләр сибеп җиргә,
Әйтте шомырт агачы:
«Җимешләргә сөйгәнеңнең
Күзе итеп карачы!»
Шомыртлар ап-ак чәчәктә,
Салкын җилләр, исмәгез.
Җимешен өлгертсен сөю,
Өметләрне кисмәгез!

❄

Уртак безгә һәрбер нәрсә,
Ай, кояш, искән җилләр,
Кошлар моңы, яфрак шавы,
Болында үскән гөлләр...

Бер синеке генә түгел,
Минеке дә ул таңнар,
Зәп-зәңгәр йолдызлы кичләр,
Чишмәләр, бөдрә таллар...
Син эчсәң бер тамчы суны,
Бер тамчысын мин эчәм.
Тик нигәдер ут-суларны
Бирүзем генә кичәм...

## Каен кызлары

Әйтерсең лә үсмер сеңелләрем,
Янәшәмдә каен кызлары.
Кон кызуы инде сүрелә төштө,
Кояш баеп бара кызарып.
Каен яфракларын үбә-үбә,
Җилләр исә талгын бер койгә.
Доньяя тулып, шушы минутларда
Әллә нинди бер нур бөркелә.
Үсмер генә чагы каеннарның,
Серсез булмас үсмер күңеле,
Каен кызларының серен тыңлыйм,
Җанга рәхәт, җанга күңелле.
Сер пышылдый алар колагыма,
Серләрендә яшьлек сафлыгы.
Каеннарга карап уйга чумдым:
Уйларымда каен аклыгы.

## Бүә җырлый

Суларның иң шифалысы
Безнең якларда бугай.
Бүәбездә су коена
Көндез кояш, төнлә ай.
Бүә буе матурлыкка
Сон буеннан ким мәллә?!
Бөдрә талы сандугачлы,
Дулкынында көнгә баккан
Төнбоегы тирбәлә.
Елга ага. Аксын гына!
Дөнья гүзәл бит шулай.
Бүә җырлый. Тыңлый-тыңлый
Күк йөзендә йөзеп йөри
Алтын кояш, көмеш ай.

## Ал тасмалы толымнар

Болын буйлап чабышып
Уйнап йөри колыннар.
Әйтерсең лә, әйтерсең,
Колыннарның яллары
Ал тасмалы толымнар.
Яңгырап тора болыннар
Кешнәгәндә колыннар.
Чәчкәләргә уралып
Җилферди күк ал тасма,
Күңелем тулы моңым бар.
Үтеп киткән елларда
Сагындырган болын бар.
Мин сагынган болынга
Киселгән шул юлларым,
Киселгәндәй толымнар.
Болын буйлап чабышып
Уйнап йөри колыннар.
Әйтерсең лә, әйтерсең,
Колыннарның яллары
Әнкәй үргән толымнар.

# Ләйсән

Чык кипмәгән иде әле
Яфракларда, үләндә.
Тәүге авазыңны салып
Дөньяга син килгәндә.
Таң белән бергә тудың син,
Балкытып бар дөньяны.
Син тәү тапкыр күз ачканда
Кырда гөлләр уянды.
Әйтерсең лә, иң-иң матур
Чәчәге син бу майның.
Сине назлап, сине җырлап
Туймас күңел тургаем.
Ә исемең матурлыгы!
Ничек кенә бит әле:
Ләйсән! Мәңге көләч яңгыр,
Табигатьнең бер ямe.

## Һәйкәлләргә баш иябез

Тимер ярчык килеп кергәч
Йөрәгенә,
Ауган алар җир-ананың
Күкрәгенә.
Җирне кочып, мәңгелеккә
Күзен йомган
Солдатларның берсе минем
Абый булган.
Еллар үткән, ә көткәннәр
Һаман көтә.
Кайтмаганнар һәйкәл булып
Басты күптән.
Батыр булып үлгән алар,
Беләбез без.
Һәйкәлләргә баш иярга
Киләбез без.

❄

Моң-зарыңны тирән яшер,
Түгелергә тормасын.
Бик тулышса, сәхрәләргә
Чыгарсың да җырларсың.

Кемдә генә юк ул моң-зар,
Тешең кысып түзә бел.
Кем күңеле яраланмый?!
Вакыт үткәч төзәлер.
Күзләреңдә тулган яшьнең
Күрсәтмә бер тамчысын.
Тагын да бер матурлыгың
Чәчәк кебек ачылсын.

## Таңнарыңны каршыла

Көтмә җилнең басылганын,
Җилгә каршы бара тор.
Сулар ничек актарылып
Ага әнә, карап тор.
Сизми калма гомереңне,
Судай агып китәр дә...
Купсын давыл, омтыл алга,
Җилкәннәрең күтәр дә.
Тормышның зур диңгезендә
Син кечкенә бер кораб.
Аңлый бел син дулкын телен,
Бар киләчәккә карап.
Киләчәгең ак болыттай
Йөзеп килер каршыңа.
Күтәрел дә колачың җәй,
Таңнарыңны каршыла.

# Нигә икән?

Тәрәзәмне ачтым, кер, язгы җил,
Күңелкәем сине сагынды.
Ис әле, ис, китсен җиләс булып,
Хисләремә ялкын кабынды.
Җилләр дәшеп тәрәз ачмый идем,
Уйсигездә чакта түзгәнмен.
Ялкынланып йолдыз күзләгәнмен,
Болыннарда чәчәк өзгәнмен.
Нигә икән бүген түзеп булмый?
Күкрәгемне куйдым җилләргә.
Йөрәгемне откан язгы ялкын,
Инде хәзер мөмкин ахры сине
Сагышларга гына тиңләргә.
Ефәк шәлеммени, йомшак җилкәй
Юатмакчы сарылып иңнәргә.

## Җиңүләрдән башка

Ничә үлеп, ничә тереләбез,
Шулай яратылган җаныбыз.
Боздай салкынайган чаклар бар, тик
Без күбрәк дөрләп янабыз.
Әкрен генә искән җилләргә дә
Кайчакларда бөгелеп калабыз.
Юк, көчсезлек түгел, без тормышның
Давылларын җиңә алабыз.
Көрәш мәйданы бу дөнья безгә
Ак биләүдә яткан чакта ук.
Җиңеләбез, янә көрәшәбез,
Җиңүләрдән башка яшәү юк.

## Бер яфрак

Өзелеп төште бер яфрак,
Сап-сары булып кипкән.
И гомерләренең үтүе,
Җәй үткән, көзе җиткән.
Яшереп куйдым яфракны
Дәфтәрем арасына.
Әй, кагылды шул, кагылды
Йөрәгем ярасына.
Җилләрнең исүендә дә
Яфраклар сарысы бар.
Үткәннәрнең җанга тулган
Моңы бар, сагышы бар.

## Күгәрчен

Тәрәзәмә килеп кунды
Күгәрчен.
Ялгыз икәнемне белгән
Күрәсең.
Әй, дускаем, ал тәпиле
Күгәрчен.
Беләм, беләм, сөйгәнемне
Күргәнсең.
Әйт дөресен, үзе генә
Идеме?
Боекмасын, мине көтсен,
Дидеме?
Тыңламый да очып китте
Күгәрчен.
Үз иңендә үз кайгысы,
Күрәсең...

❄

Шыгыр-шыгыр ашыкмыйча
Кемдер үтте урамнан.
Рәхмәт яусын, арындырды
Эч пошыргыч уйлардан.

Кар шыгырдый, гүя кышның
Миңа шигырь сөйләве.
Яңа туган рәхәтлекнең
Кардай ап-ак биләве.

# Күңел

Бар бит ул күңелнең,
Бар кинә, бик тары,
Йомшагы, катысы,
Яктысы,
Утлысы,
Хислесе,
Серлесе,
Керлесе,
Моңлысы-зарлысы,
Бик бас, ярлысы,
Бозлысы-карлысы.
Күңелләр әрни дә, рәнҗи дә,
Сыкрый да, елый да.
Барын да берьюлы онытып
Җырлый да.
Җыр булган күңелдә
Өмет бар, шатлык бар.
Зарлыны юатыр,
Катыны йомшартыр,
Бозлыны эретер,
Керлене агартыр
Сафлык бар.

❄

Бу — донья, шушы доньяга
Тудырган сине ана.
Эчэсең килсэ чишмэ бар,
Өшесэң учак яна.
Менэргэ дисэң бар тавы,
Өзэргэ голе үсэ.
Давылы алса хэлеңне,
Иркэлэп җиле исэ.
Бар да бар, чыга кояшы,
Яңгыры ява, кары.
Донья зур, азсынма, яшэү
Бер гомер генэ бары.
Бер гомер очен анаңа
Мең рэхмэт эйт син, бала.
Доньяга сине тудырып
Ул җанын утка сала

## Иртэ килсен язлар

Гол үстерик, язны котеп тормыйк,
Җылы орсэк голлэр үсэр кебек.
Бүген түзик, иртэгэсе конгэ
Талгын җиллэр генэ исэр кебек.
Кар таулары ята язны котеп,
Юкмы эллэ бездэ язгы ялкын?!
Без күрешкэч донья җылыначак,
Кон бүгенгэ генэ шулай салкын.
Ашыктырыйк лэйсэн яңгырларын,
Вакытыннан иртэ килсен язлар.
Без китергэн язлар имин булсын,
Парлы-парлы булып кайтсын казлар.

Рәфис
МӨХӘММӘТДИН

# ЧАКЫР МИНЕ





# Үзем турында



Мин, Мөхәммәтдинов Рәфис Нәҗип улы (әнкәем Ракыйбә исемле), 1960 елның 28 февралендә Башкортстанның Яңавыл районы Яңа Уртавыл авылында гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килгәнмен.

Бала – гаиләнең шатлыгы гына түгел, кайгысы да икән ул: минем язмыш җиңелдән түгел, бала чагымнан ук үз аякларыма басып йөри алмыйм. Әткәем инде вафат, әнкәем тәрбиясендә яшим. Укытучылар өйгә килеп укырга-язарга өйрәттеләр, мәктәпкә йөреп белем алырга насыйп булмады. «Беренче группа инвалидмын» дип күңел төшенкелегенә бирелмәдем, кулыма каләм алдым.

Язган мәкалә, шигырь, хикәяләрем бүгенге көнне Башкортстанда һәм Татарстанда чыккан гәзит-журналларда даими басылып тора. 1994 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Яңавыл бизәкләре» дигән күмәк җыентыкта 24 шигырем дөнья күрде. Мине Башкортстанның татар язучылар берлегенә әгъза итеп кабул иттеләр. Берничә шигырем көйгә салынып, җыр булып яңгырый. Менә шуларның һәммәсе инде минем күңел канатларым!

Язмыш никадәр авыр булса да, бирешеп калырга теләмим, соңгы сулышыма кадәр көрәш дәвам итәчәк. Янып яшәү, янып эшләү үзе бер бәхет!

*Автор.*

## Үзем булып калам

Әйткәннәре булды миңа:
«Тормышта хаклык сирәк.
Күзле килеш сукыр булып
Калуың хәерлерәк!»

Ишетмәдем, әллә шуңа
Бик күпләр иш итмәде.
Хәтта дустым табынында
Кайчак урын җитмәде.

Үзем булып калам һаман,
Сойлимен үз сүземне.
Хаклык күреп яшәр очен,
Ачтым ласа күземне.

## Юк, әйталмам!

Карлар эри, тып-тып тамчы тама,
Гүя дәртле йөрәк кагышы.
Ярларыннан ташкан елгаларның
Ишетеләә шаулы агышы.

Бөреләнә инде тал-тирәк тә,
Сусагандыр былбыл җырына.
Күз алдымда гөлләр тармаклана,
Үрмәлиләр кояш нурына.

Сокландыргыч язгы бу мизгелләр,
Күңелемне кабат яшәртә.
Юк, әйталмам, доньям, туйдым диеп,
Әллә ничә гомер яшәп тә.

## Татлыдан да татлы

Йөрәк җырым, сандугачым,
Моңлы сабан тургаем,
Дип атасам аны, дускай,
Ялгышмамдыр, мөгаен.

Алтын-көмешләрдән затлы,
Юкә балыннан татлы,
Дип зурласам аны, дускай,
Булырмындыр мин хаклы.

Нурлы, назлы, миһербанлы,
Гүя әнкәм күңеле,
Дисәм Туган тел хакында,
Минме хаклы түгелмен?!



# Җиңү кɵнендә

*Әткәй сугыш яланыннан Җиңү белән кайткан кеше иде. Җиңүнең илле еллыгын бәйрәм итә алмады шул.*

Илдә бәйрәм бүген, зур тантана,
Яз нурлары халкым йөзендә.
Әткәй, синең яудашларны күрәм,
Яшь бɵртеге минем күземдә.

Һәр ел саен тугызынчы майны
Бәйрәм иттек уртак табында.
Әле бик күп еллар гел шатланып
Яшәр кебек идек янында.

Ул кɵннәрне уйлап, күңелкәем
Ɵзгәләнеп сине сагына.
Язның тәүге чәчәкләрен җыеп,
Инде килдем каберең янына.

# Ышанам

Әлләнинди үзгә матур бу көн,
Тирә-юнем бүген ап-актан.
Яңа елның тәүге ак карлары
Очып-очып уйный як-яктан.

Бөтен доньл бүген пәкъ шушылай
Төренгәндер дисәм аклыкка,
Илдә сугыш, кан исләре аңкый,
Юл өзелә шатлык-хаклыкка.

Чечня, синең өсләреңә бүген
Җир-күкләрдән тобәп аталар.
Йөз-меңләгән халкым башын сала,
Нигә кабатлана хаталар?!

И Ходаем, явыз Гитлер да бит
Үз халкына үзе атмаган.
Гонаһлы булмас бу эш өчен
«Фашист» диеп безне атаган.

Яңа елның тәүге кары ява,
Тирә-юньне төреп аклыкка.
Чечня җирендә дә кояш балкыр,
Мин ышанам шушы хаклыкка.

*гыйнвар, 1995*

❄

Тәрәзәмә таш аталар,
Ваталар пыяласын.
Беләләр останың килеп
Яңадән куяласын.

Күңелемә таш аталар,
Беләләр уаласын.
Нинди оста куяр икән
Күңелем пыяласын?!

## Күршеләр

Айлар буе бер-бербезгә
Бер кәлимә дәшмибез.
Араларны читән аера,
Тергәлешеп яшибез.

«Күрше хакы – тәңре хакы»,
Дисәләр дә, эре без.
Беребез – олы, икенчебез
Кече булмый йорибез.

Юкка-барга сүзгә килеп,
Рәнҗетәбез күңелне.
Без соң фани доньяларда
Кунак кына түгелме?!

❄

Елга ярсып ташса ярларыннан,
Тирә-якка чыгып тарала.
Су астында калган ялан-кырлар
Үз төсләрен җуя – карала.

Әгәр күңел ташса, авызыңнан
Яхшы, яман сүзләр түгелә.
Хак-нахакмы – кая карап тору,
Кызулыктан кемдер сүгелә.

Ташкан сулар кайткач, карайган җир
Кояш нурларыннан яшәрер.
Тик нахакка рәнҗетелсә кемдер,
Гомере буе күзе яшьләнер.

## Елан

Кара елан чагып та ул,
Исән калды – үлмәде.
Бөтен авырлыкны җиңеп,
Гел яктыга үрләде.

Хөрмәтләде аны һәркем,
Күз уңыннан төшмәде.
Гел мактауга ласк булып,
Матур эшләр эшләде.

Канатланып яшәде ул,
Дәртләнеп донья куды.
Ә ахырда «яшел елан»
Чагудан доньья куйды.

## Таш бәгырь

Ана көтеп газиз улын
Инде күпме таң ата.
Шахтер егет – аның улы,
Ничәмә ел таш вата.

Ялгыз ана яшен түгеп,
Йота соңгы ашларын.
Нигә егет ватмый икән
Үз бәгыре ташларын?!

## Ана зары

Тәрәзәмнән күзли-күзли,
Тала ике күзем.
Өч улымнан ялгыз калдым,
Бир, Ходай, бир түзем!

Сәгатьләр – кон, коннәрем – ай,
Авыр үтә вакыт.
Хәлләремне белүче юк,
Кайтып ишек шакып.

Әшегез күп шул, балалар,
Дөньялыкта, харап!
Тотсагыз иде, ичмасам,
Каберемне карап!

## Ник туганнар

Һич туктауны белми көзге яңгыр,
Тишек түбәсеннән су ага.
Салкын өйнең тәрәзәсе аша
Моңсу гына ике күз бага.

Өч баласы ерак – чит якларда,
Яши дилэр хәлле, типтереп.
Ә берсе дә ялгыз әнкәсенә
Хәт утынын бирми китереп.

Аналар да гомерлеккә килми...
Ана авырып китте беркөнне.
Күршеләре телеграмма сукты,
Тик кайтмады аның беркеме.
Соңгы минутына кадәр көтте,
Өмет өзелмәде анада.
Балалары йөгерешеп кайтты,
«Үлде» диеп суккач яңадан.

Озатып та җитми соңгы юлга,
Бу нигездә мәхшәр башланды.
Барлы-юклы калган милкәтләргә
Балалары аның ташланды.
Их, балалар!..

*

Яралы кош килеп кунды,
Кан тама ярасыннан.
Канатлы да бит, барыбер
Сызлана минем сыман.

Ярдәм кулларымны сузып,
Үрелдем, җитми буем.
Аңладым, бүген аңладым,
Язмышлар түгел уен.

*

Шакыдың, рөхсәт сорадың,
Ачтым ишек келәсен.
Әйттең: «Күптән очрашкан юк,
Килә сине күрәсем».
Син дә хаклы, әт-мәчедәй
Күпме була яшәргә!
Бик авырлык белән генә
Базнат иттем дәшәргә.
Теләсәң дә, сүз ярасы
Онытылмыйдыр, күрәсең.
Ачуланма, мин ачалмам
Йөрәгемнең келәсен.

❄

Коляскама килеп тотынды да:
«Мескен...»,– диде исерек бер бәндә.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә әйтте:
«Күрми яшисең бит бер ямь дә».

Җирәндергеч йөзен күрмәс өчен,
Карашымны бордым читкәрәк.
Хәтерем калып аның сүзләренә,
Ачу белән әйттем: «Ни кирәк?»

Көчкә-көчкә аягына басып,
Яктан-якка китте сугылып.
Ерак баралмады, юл читенә –
Бер чокырга төште егылып.

«И бичара!»– дидем, көлемсерәп:
– Син мескен дә түгел аяклы.
Син исерек, миндә аек акыл,
Кем мескен соң монда, кем хаклы?!»

## Болында

Казлар чыкты, бәбкәләре
Яшел үлән чүпләп йөри.
Чәлдерергә бәбкәләрен
Бер тилегән читләп йөри.

Ата каз, һай, сизгер бит ул,
Тилегәнне куып китте.
Башка яктан икенчесе
Ни арада килеп җитте.
Аналары бирәме соң,
Җыеп алды канатына.
Ә мин уйлыйм ятимнәрне,
Йөрәгемнән кан атыла.

## Шигырь язам

Чыккан саен авыл урамына,
Тау күргәндәй карыйм дөньяга.
Баласына җим ташыган коштай,
Илһам алып кайтам ояга.

Чишмә суларыдай күкрәгемнән
Ташып чыга минем хисләрем.
«Әреме дә якын» дип җырласам,
Һич китмәсен, кешем, исләрең.

Мин гашыйкмын айлы кичләремә,
Сызылып аткан алсу таңыма.
Бәхетле мин синдә, каләмемне
Манып язам йөрәк канына.

## Хата

Хәтеремдә, әнә шулай берчак,
Нидер үтеп аның янына,
Әйткән иде күршем Ахун абзый,
Җыелгач бер капка янына:

«Авыл җирләрендә без кичергән
Газаплар да җитәр, балалар.
Рәхәтлектә үтсен гомерегез,
Сезне көтә бүген калалар!»

Урамнарга чыккан бу сүзләре,
Әйтелсә дә ое түрендә.
Биш баладан ялгыз торып калды
Ишек ачылганчы гүренә.

Нигез ташын чүп үләне басты,
Мәңгелеккә йомгач күзләрен.
Бу турыдан үткән чакларымда
Хәтерлимен әл дә сүзләрен...

## Кошлар күрсәм...

Язгы җилләр талгын гына
Тәрәзәмә килеп какты.
Урамнарда гөрләвекләр
Борма-борма юлын тапты.

Шаулап-шаулап гөрләвекләр
Елгаларга карый акты.
Моңлы-җырлы очар кошлар
Туган җирләренә кайтты.

Кошлар кайта язлар саен,
Сагынып туган ояларын.
Әллә нигә кошлар күрсәм,
Үз-үземнән оялармын.

❄

Ага чишмә чылтыр-чылтыр,
Яннарында таллары.
Суын алып авыз итсәң,
Яктыра күз аллары.

Чишмә буе таллары да
Җаннарга якын, үзгә.
Сандугач та моң телендә
Әйтергә тели безгә:

«И кешелек, туган җирдә
Синең күрер шатлыгың.
Саклап кына тот кадерләп
Талларыңның яшеллеген,
Чишмәләрнең сафлыгын!»

## Сагыну

Кичке моңнар агыла авылымда,
Яшьләр йөри гармун уйнатып.
Тәрәз читләреннән качып кына
Әбекәем кала күз атып.

Сагынадыр ул да яшь чакларын,
Күзләп кала авыл яшьләрен.
Урамнарга моң агылган чакта
Күзләрендә күрәм яшьләрен...

## Сәламлимен язны

Язлар җитте, горләвекләр булып
Ага кышның соңгы карлары.
Сабантуйга җилгән аргамактай,
Күтәрелә җирнең парлары.

Җир уяна сабый йокысыннан,
Иркәләнеп кояш нурына.
Талгын исә җил дә, Җир гөнәне,
Яшь анадай, ахры, курына.

Ничек итеп җирне курынмассың,
Сызланмассың ничек җир диеп.
Менә әле шаулы, имин язны,
Сәламлимен җиргә баш иеп.

Тәүге адымымны нык-нык басып,
Атлап киткәнмен ич мин синдә.
Синдә булган кайнар союемне
Тоясыңмы, җирем, син миндә.

## Еракtагы дусларга

Берәү дәшә: «Кил син безгә,
Төзеп бирәм зур пулат.
Җәннәткә тиң булыр әче,
Яшәрсең иркен сулап».

Берәү әйтә: «Кил син безгә,
Сайрый оҗмах кошлары.
Ел әйләнә җимеш ашыйм,
Булмый салкын кышлары».

Туган якның салкыны да
Җаныма бирә рәхәт.
Китәмме соң туган җирдән,
Хөрмәтегезгә рәхмәт.

Беләм бит мин киткәннәрнең
Үкенеп яшәгәнен.
Сагышлардан күзләремнең
Телә мим яшьләнгәнен.

## Аерма

Бәхетне шул Ходай тигез бүлми,
Биргәненә – бирә тау өеп.
Сәламәтлек булса, бүген сиңа
Утырыр идем әллә баш иеп?!

Давылларда торып калганмын шул,
Язмышыма яшим буйсынып.
Кирәк түгел миңа синең байлык,
Кызыктырмый синең буй-сының.

Тик, туганым, сиңа бер үтенеч:
Очар канатымны каерма.
Син җанымны аер минем тәннән,
Туган җирдән мине аерма!

❄

Йөзләремә карап гаҗәпләнмә,
Нигә болә диеп күзләрем.
Шатлыклардан гына көлеп була,
Шатлыклардан шулай үзгәрдем.

Шатланам мин чыгып кырларыма,
Тирәктәге кошлар моңына.
Туган якта гына ишетелгән
Чишмәләрнең көмеш чыңына.

Туган авылыңда гомер итү
Кеше өчен нинди горурлык!
Оҗмахы да хәтта кирәк түгел,
Йотым суы шуңа торырлык!

## Үкенмәссеңме?

Син сукырсың бүген, саңгыраусың,
Ишетмисең кошлар сайравын.
Күрмисең шул болыннарга чыгып
Якташыңның чалгы кайравын.

Яшисең син шәһәр уртасында,
Дус-иш белән дөнья куасың.
«Торган җирем җәннәтләргә тиң»,– дип,
Күкрәгеңне каккан буласың.

Күрәм: бүген синең алларыңда,
Җәйрәп ята «байлык» диңгезе,
Үкенмәссең микән беркөн килеп,
Бетергәнгә атаң нигезен?!

# Кайту

Челтәрләнгән инде кар-осмнәр,
Яз кояшы карый доньяга.
Горләвекләр ага, елга таша,
Кошлар кайта туганояга.

Канатлылар, нинди бәхетлеләр,
Туган җирдә оя янарта!
Шатлыклары тышка бәреп чыгып,
Тирә-юньгә моңын яңгырата.

Бер бабай да кайткан туган якка,
Түбән иеп йөри башкаен.
Кире борып булса гомер угын,
Салыр иде нигез ташкаен!..

❄

И туган җир, синдә генә
Бөтен күргән матурлык.
Туфрагың да синең мамык,
Түшәк итеп ятарлык.

Чишмәләреңң тәмле суын
Туя белми йотарлык.
Тәлгәш-тәлгәш җимешләрең
Тел очында тотарлык.

Үзгә синең кояшың да,
Үзгә сулар һавасы!
И туган як, туган авыл,
Синдә йөрәк дәвасы!
Тик еракка киткәннәрне
Кире сиңа кайтарырга
Нинди чара табасы?!

❄

Сорамыйм синнән, сорамыйм,
Ник боек, дип, күңелең?
Беләм бит, болай да беләм
Сиңа җиңел түгелен.

Язлар житте, йомшак җилләр
Җиргә ятып кар ашый.
Горләвекләр агып төшеп
Елга, чишмәләр ташый.

Туган ягын сагынып кайтып
Кошлар бит оя ясый.
Талпынып ла үз ягына,
Синең йөрәгең ярсый.

## Туган җиргә җитми

Туган авылым, сине сагынып кайтам,
Торган җирләр яхшы булса да.
Сине ташлап чыгып китүемә
Инде дистә еллар тулса да.

Авылкаем, сине сагынып кайтам,
Чылтырап аккан чишмә суларын.
Балам, диеп каршы чыгып кочкан
Әнкәемнең җылы кулларын.

Туган авылым, сине сагынып кайтам,
Торган җирләр оҗмах булса да,
Туган якка, дуслар, җитми икән,
Алтын таулар алда торса да.

## Иртәнге җыр

Бакча арты яшел болын,
Ак чәчәккә төренгән.
Талларында кошлар сайрый,
Чылтырап ага чишмәләре,
Бар табигать терелгән.
Очып уйный күбәләкләр,
Гүзәллеккә гүзәллек.
Җәйге иртә, мин бит гашыйк,
Сиңа гашыйк, хәлләрем юк
Җырламыйча түзәрлек.

## Шигъри хат

Авылымның гүзәллеген күреп
Читкә киткәннәрне кызганам.
Шулар арасында туганнар бар,
Әллә шуңа бигрәк сызланам.

Җәйге кичтә чыгам урамнарга,
Чишмәләрнең чыңын ишетеп.
Сандугачлар энә безгә җырлый,
Үзләренә күрә иш итеп.

Талгын гына йомшак җилләр исә,
Авыл һавасына назланам!
Сез тоймыйсыз шушы рәхәтлекне,
Туганнарым, шуңа сызланам!

Кунак булып кына авылларга
Кайтасыз да кире китәсез.
Кире киткән булып җаныгызны
Шатлыклардан мәхрүм итәсез!

## Басуда

Карлар эреп, җир-су кипкән инде,
Яшәргәннәр урман-кырларым.
Игенчеләр чыга басуларга,
Тыцлый-тыцлый тургай җырларын.

Йомшак кына язгы җилләр назлап,
Игенченең тарый чәчләрен.
«Уцышлы җәй килсен»,– диеп әби
Дога кыла иртә-кичләрен.

❄

Әйдәләмәгез лә инде,
Килми минем китәсем.
Килми туган җирләремнән
Җанны мәхрүм итәсем.

Килми минем кабатлыйсым
Бүтәннәрнең хатасын.
Доньялыктан аерылгач,
Чит җирләрнең туфракларын
Түшәк итеп ятасым.

## Зур байлык

Игенчеләр чыкты кырга,
Корыч атларын җигеп.
Ышанам уңганнарыма,
Кайтырлар алар җиңеп.

Басу өсте сары башак,
Өлгергән инде арыш.
Бөртеген дә югалтмаска,
Тырыш, игенчем, тырыш.

Игеннәрем бигрәк уңган,
Бураларыбыз тулыр.
Хезмәт сөючә халкыма
Иң зур байлык шул булыр.

## Язны көткәндә

Котырынып февраль бураннары
Тәрәзәмә килеп сырыша.
Якынлыгын сизеп Яз сылуның,
Биреशмәскә, ахры, тырыша.

Күңме генә тырышмасын кышым,
Бакый канун сүзен сүз итәр.
Җанга җылы назын һич кызганмас,
Миңә тагы җиргә яз җитәр.

Кырларына чыгар игенчеләр,
Тургай кайтыр зәңгәр күгенә.
Килер язның яме, кошлар моңы
Җырлар булып керә күңелемә.



## Көзге таңда

Көз — көз инде, имәннәр дә
Сарыларга сарыла.
Көз сарысы сагыш булып
Күңелләргә кагыла.

Ялгызларга бигрәк авыр
Ак томанлы таңнарда.
Көзге җилләр, кагылмагыз,
Яз бар әле җаннарда!

## Туган җирдә калыйк

Яшьлек юлларлегең белән,
Канат тоясың иңдә.
Очам дисең чит җирләргә,
Кошларга карап син дә.

Кошлар вакытлыча китә,
Кайта алар яз җиткәч.
Сагынсаң да кайтулары
Читендер ул бер киткәч.

Әйләнеп тә кайтулар бар,
Тик оя тузган була.
Дәрт булса да, дәрман калмый,
Яшь гомер узган була.

Кошлар китә, янә кайтыр
Язын оя яңартып.
Яшик әле читкә түгел,
Туган җиргә җан атып.

❄

Җирне тырный-тырный елый,
Дәрья аның күз яше.
Өзгәләнә хатын җаны,
Донья куйды интәше.

Авыл халкы чыш-пыш кылә:
«Бик яшь калды бичара.
Тиңе чыкса янә чыгар,
Табалмас башка чара».

Бер тол хатын әрнү катыш
Әйтеп куйды шул ара:
«Беренчесе булмый шул ул,
Хет меңгә барып кара».

## Әнкәйгә

Мин бәхетле, бик бәхетле:
Әнкәм янымда бүген.
Яктырта иң назлы кояш
Күңелем зәңгәр күген.

Тәрәз саен шау чәчәктә
Җәен, кышын гөлләрем.
Син булганга гына, әнкәм,
Якты минем көннәрем!

Әнкәй, чәчең ап-ак болыт,
Карашларың таң нуры.
Син бит җирдә минем өчен
Бәхетемнең иң зуры!

## Ялгыз калгач

Инеш буе бүген моңга чумган,
Тирәкләрдә җырлый сандугач.
Әнкәем дә килгән монда бүген,
Чәчәк кенә чагын сагынгач.

Очраткан ул тәүге мәхәббәтен,
Кер чайкаган чакта басмада.
Шул көн эткәй ат эчерә төшкән,
Йөгәннәрен бизәп тасмага.

Кер чайкыйлар кызлар, ә егетләр
Ат эчерә, тарап ялларын.
Моңсу гына әнкәй күзләп тора,
Куяр урын тапмый җаннарын.

❄

*(Сеңлемне бәбие белән күргәч язылган шигырь)*

Күз алдымда синең бүгенгедәй
Уйнаганың, сеңлем, курчаклы.
Инде хәзер үзең ана булдың,
Һай, тиз үтә гомер шул чаклы.

Йөрәгеңнән төшкән җимешеңне
Күкрәгеңә кысып син кердең.
Аналарга гына хас шатлыкны
Йөзләреңә карап мин күрдем.

Берүк кенә бала кайгылары
Бәгырь итләреңне телмәсен.
Гел кояшлы булсын туар көннәр,
Тормышыңа хәсрәт килмәсен!

# Гашыйк кызларга

Әбисенә серен ачты,
Түзәлмәде Нурсибә:
– Бер егеткә гашыйк булдым,
Йөзләремнән нур сибә.

Озата килде артымнан
Кара кашлы зәңгәр күз.
Буй-сынына, төсләренә
Тидерерлек түгел сүз.

«И, чибәрем, киләсеңме?
Тик сине генә алам»,–
Ди ул миңа, нишлим, әби?
Сүзен әйтте әби шулчак:
«Төс туйда гына, балам».

## Шигырем кемгә язылган?

*К*өннәремнең син кояшы,
*Ә* төнемнең зур ае.
*Ү*зәкләрне бер моң өзә,
*С*андугачлы май ае.

*Ә*нә кошлар тирәкләргә,
*Р*әт-рәт парлап тезелгән.
*И*шет йөрәк тавышымны,
*Я*нә сиңа кабатлый ул:
*М*индәй юктыр синең өчен,
*Ә*й, юктыр ла өзелгән.

## Учак яктым

Өшеп, туңып учак яктым
Алларыма.
Очкыннары очып төште
Яннарыма.

Битләремне өтеп ала
Ялкыннары.
Җаннарымны куыра тормыш
Салкыннары.

Учак яктым, кил син минем
Яннарыма.
Авырлыкны җиңәр көч бир
Җаннарыма.

❄

Тәңкә-тәңкә карлар ява,
Кулларым иңнәреңдә.
Без бәхетле пар аккоштай
Мәхәббәт илләреңдә.

Нинди ләззәтле минутлар,
Йөрәктә яшьлек хисе.
Әйтерсең, яз, синнән бөрки
Чәчәкләрнең хуш исе.

Сиңа төбәлгән карашым,
Сабый күңеледәй керсез.
Ай, йолдызлар безгә шаһит,
Пышылдап әйтәм бер сүз...

❄

Тормыш бит ул ярсыз дәрья,
Бер ялгызың йөзәсең.
Дулкыннары бәрә, кага,
Тешең кысып түзәсең.

Тормыш бит ул ярсыз дәрья,
Ялгыз ничек узарсың?
Дәрьяларны кичәр өчен,
Пар канатың булып сиңа,
Килә кулым сузасым!

## Килер язлар бар әле

Көзләр җитте, сары яфрак коя
Яр буенда үскән бөрлегән.
Су өстендә пар аккошлар йөзә,
Ялгыз итмә мине, бергенәм!

Көз салкыны булып берүк кенә
Йөрәгемне итмә яралы.
Бөрлегәннәр янә бөреләнер,
Безнең килер язлар бар әле.

## Нишләрмен

Күкләрем зәңгәр булса да,
Кояш нурлы булырмы?
Язлар җиткәч елгаларым
Ташып ярга тулырмы?

Болыннарда, тугайларда
Гөлләр чәчәк атырмы?
Кыр казлары, сандугачлар
Сагынышып кайтырмы?

Беләм-беләм, язлар килер,
Сайрар моңлы сандугач.
Мин гүзәллек күрерменме,
Син янымда булмагач?!

# Кыш һәм чәчәкләр

Зәңгәр күкләргә карадым,
Ап-ак болытлар ага.
Кышлар җиткән – гөлләр туңган,
Сабакларын җил кага.

Энҗе булып кар сибелә,
Күңел гөлем чәчәктә!
Гөлләрем туңмас, син ташлап
Китмәсәң киләчәктә!

❄

Көннәрең көнлим кошлардан,
Төннәрең тулган айдан.
Сиңа гына бу гүзәллек
Килгән соң, белмим, кайдан!

Йомшак җилләрдән көнләдем,
Нечкә билле талдан да.
Бер минутка да җибәрми
Тотам гел күз алдымда.

Карашларың читкә борма,
Бел, барыбер каратам.
Көнләшә димә, кадерлем,
Сине өзелеп яратам!

## Авылым чибәренә

Яратам мин, яратам мин
Язын таңнар атуын.
Язгы таңнар аткан чакта
Кыр казлары кайтуын.

Ни өчен мин яратаммы
Язгы кояш нурларын?–
Язгы кояш нуры булып
Бар дөньямны нурладың.

❄

Талгын гына җилләр исә,
Син шул җилләр булам, дисең.
Ач күңелең ишекләрен,
Гел наз булып тулам, дисең.

Бел, болай да син җанымда
Мәңге сулмас бер чәчәгем.
Бул җилем, бул гөлем, булма
Тик давыллы киләчәгем.

❄

Сагышларга салып китмә,
Иркәм, салкын кышларда.
Кышкы көннәр ямансу бит,
Сайрамыйлар кошлар да.

Кышкы көннәр салкын була,
Елгалар, күлләр туңа.
Китәм дисең ераkларга,
Күңелем боек шуңа.

Бозлары киткәч елгалар
Ярсып агарлар инде.
Китмә, китмә: син боз түгел,
Сагышка салма мине.



# Кышкы кичтә

Кышкы кичтә чык син урамнарга,
Һавалардан энҗе коела.
Ап-ак карлар җәйге күбәләкләр
Очып уйнагандай тоела.

Кышкы кичтә авыл урамнары
Сихри ямьгә, моңга күмелә.
Туй күлмәге кигән агачлар да
Җырлагандай була күңелгә.

Ямьле кичтә бергә булыйк әле,
Әйдә, иркәм, әйдә урамга.
Тормыш юлларыннан яңәш атлап
Каршы барыйк салкын буранга.

# Гашыйк егет җыры

Авылымның урамнарын
Басты кар бураннары.
Бер күрүдә гашыйк булдым,
Шулдыр тиң булганнары.

Көн дә, көн дә килеп тора
Яннарыңа барасым.
Ничекләр якынайтасы
Чакырымнар арасын?

Беләм, хисләр тоташтырыр
Ике авыл арасын.
Мәхәббәтнең көче җитәр
Табарга бер чарасын.

# Син мине ярат әле

*(җыр)*

Якты аем, йолдызым бул,
Кояш булып көл әле.
Сандугачын көтә күңел,
Язлар булып кил әле.

Сандугачлы язларымның
Матурлыгын күр әле.
Өзеп биргән гөлләремне
Чәчләреңә үр әле.

Ал таңнарның нуры булып,
Иркәләп уят әле.
Әллә ниләр булды җанга,
Күңелемне юат әле.
Тибрәндереп назларыңда,
Кайгымны тарат әле.
Яктыртып күз алларымны,
Дөньяга карат әле,
Син мине ярат әле.

# Күзнең дә бар җылы җиле

Күзгә җилләр тәрәз какса,
Гөлләрең читкә алма.
Җилләр булып мин килермен
Туңып, бөрешеп калма.
Гөлеңә дә, үзеңә дә
Бирәм мин җан җылымны.
Күзнең дә бар йомшак җиле,
Шул җилләрнең исүендә
Ишет йөрәк җылымны.

# Кояшым бул

*Кәүсәриягә*

Яз аеның көмеш тамчысына
Охшатам мин синең күзеңне.
Гомеремнең якты таңнарына
Тиңлим синең нурлы йөзеңне.

Тавышыңны бер көн ишетмәсәм,
Югалткандай булам көнемне.
Мәңге сүнмәс яз кояшым бул син,
Шау чәчәк ит күңел гөлемне!

## Түгәрәк дөнья

Чәчәкләрдән чәчәкләргә
Очып куна күбәләк.
Торле төстә чәчәк җыеп
Үрәм сиңа бер бүләк.
Без бәхетле бүген, дөнья
Такыядай түгәрәк!
Берүк, иркәм, киләчәктә
Була күрмик күбәләк!

## Белмәдем

«Ниләр булды, уйга чумдың»,-
Дип сорадың миннән.
Түкми-чәчми серем чиштем,
Һич яшерми синнән.

Йотылыплар син тыңладың
Минем сөйләгәнне.
Белмәдем шул синең мине
Аңлый белмәгәнне.

❄

Кешнәр буе болыннарда
Үз чәчәгем эзләдем.
Күпме чәчәк сибә нурын,
Тик берсен дә өзмәдем.

Эзли торгач, үз чәчәгем
Табып алдым кулыма.
Өзә күрмә ят гөлләрне,
Нур сипсә дә юлыңа!

# Гөл үстерә минем иркәм

Гөл ярата минем иркәм,
Тәрәз төбе саен гөл.
Туфракларын алмаштырып,
Тәрбияләп тора гел.

Ал, ак, кызыл, көрән, зәңгәр
Чәчәк ата гөлләре.
Гөлләредәй матур булсын
Һәрчак аның көннәре.

Гөл ярата минем иркәм,
Гөлләрдәй саф күңеле.
Бу гүзәллек йөрәгемдә
Сөю хисе булып таша,
Яшәү нинди күңелле!

## Чәчәк бүләк итәм

Сафлык тосен – язгы чәчәкләрне
Бүләк итеп бирдем сак кына.
Безнең күңел шомырт чәчәгедәй
Булсын әле шулай ак кына.

Шул аклыкның кадерләрен белеп,
Кагыла күр, иркәм, сак кына.
Язлар да бит гөлләр белән матур,
Сөюебез булсын саф кына.

Шомырт җимешенең каралыгы
Тапламасын хисләр аклыгын.
Син – минеке, мин – синеке мәңге,
Тоеп яшик сөю шатлыгын.

## Бербөтен

Карлы-бозлы яңгырларга кереп
Адаштыммы әллә мин бүген?!
Кара болыт каплый күкләремне,
Мин кичәге кебек түгелмен.

Язмышымның бозлы яңгырлары
Күшектерде, алды хәлемне.
Якты дөнья, кабат күрерменме
Кояшыңны, синең ямеңне?

Үз-үземне шуңа ышандырам:
Өзелмәгән әле өметем.
Йончулардан мине арындырыр,
Мәхәббәтем әле бербөтен.

## Дулкын кочагында

Ярдан-ярга дулкын бәреп,
Алдыбызда елга ага.
Безне тормыш дулкыннары
Әнә шулай бәрә-кага!

Безне тормыш кыенлыгы
Әле озак сынар микән?
Сабырлыклар чыдар микән,
Көче бетеп сынар микән?

Юк, җиңалмас авырлыклар,
Йөрәкләрдә көчле ташкын.
Яшәүгә көч-кодрәт биреп,
Мәхәббәтем, әйдә, ашкын!

# Рәхмәт!

Очар кошмы әллә бүген үзем,
Шатлыгымнан канат кагынам.
Доньялыкта бүген тик бер Ходай,
Ул син, иркәм, сиңа табынам.

Йөзләреңнән балкый үзгә бер нур,
Яннарыңда синең и рәхәт.
Җаннарыма биргән җылың өчен,
Мәхәббәтем, сиңа мең рәхмәт!

# ЭЧТӘЛЕК

Рухи каһарманлык. *Фәрит Габдрәхим* . . . . . 3

Көннәрем гөлләр кебек. *Кәүсәрия Шафикова*

Үзем турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Кызлар җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Иманым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
«Кагынам да, күңелләрнең...» . . . . . . . . . . . 15
Чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Әнкәйне юксыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Кошлар кайтыр! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Төймәле кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Күршедә малайлар үсә . . . . . . . . . . . . . . . 18
Заман җиргә күктән төшми . . . . . . . . . . . . 19
«Яфракларны агачыннан...». . . . . . . . . . . . 21
Авыр көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Кояшлы буран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Күрше апага . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Мин татар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Алтын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
«Үсмер чакка кайтыр идем...» . . . . . . . . . . 24
Мин ышана идем кешеләргә . . . . . . . . . . . 25

«Кайтыр юлда кошларның да...» . . . . . . . . 25
Күз яше . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
«Укытучы дия идем сине, тормыш...» . . . . . . 26
Син көткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Сабантуйлар җитте . . . . . . . . . . . . . 28
«Мәхәббәт дип сөенеп яшимен...» . . . . . . . 29
«Бәхетсезлек нигә килде...» . . . . . . . . . 30
Җырлап яшә . . . . . . . . . . . . . . . . 30
«Кеше хәлен кеше белсен иде...» . . . . . . . . . 31
«Чәч агара, теш коела...» . . . . . . . . . . 32
Карлы иртә . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Кайтып әйләп . . . . . . . . . . . . . . . 33
«Күз яшьсез дә үксеп-үк еп...» . . . . . . . . . 34
Сынар өчен . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Сер сөйләдем . . . . . . . . . . . . . . . 35
Тал икән . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Иң матур җыр . . . . . . . . . . . . . . . 36
Бүген җилләр талгын исте . . . . . . . . . . 37
«Ай түгәрәк икән..» . . . . . . . . . . . . 37
Кыр казлары . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Гаилә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
«Баланыгыз бигрәк уңган...» . . . . . . . . . . 40
«Агачлар, ничек сынмыйсыз...» . . . . . . . . 41
Кайттым . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Көчле бул . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
«Ашыктырып дәшә юллар...» . . . . . . . . . . . 42
Күзләреңә бактым . . . . . . . . . . . . . 43
«Әллә нигә шигырь язылмый...». . . . . . . . . . 43
Чәчәк өши . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
«Кайнар яшен түгә күзләр...» . . . . . . . . . . 44
Яшел яфрак . . . . . . . . . . . . . . . . 45
«Врач булсам, мин дәвалар идем...» . . . . . . . 45
Ялгызларга . . . . . . . . . . . . . . . . 46
«Бишегемдә чагымда да...» . . . . . . . . . . 46
Аерылмыйк . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Кунакка кайткан берәүгә . . . . . . . . . . . 49

«Берәү сөйли күргәннәрен...» . . . . . . . . . . . . . . 50
Кеше көчле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Күзләремә карап кол . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Шомырт – мәхәббәт агачы . . . . . . . . . . . . . . . 52
«Уртак безгә һәрбер нәрсә...» . . . . . . . . . . . . . 52
Каен кызлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Бүә җырлый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Ал тасмалы толымнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Ләйсән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Һәйкәлләргә баш иябез . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Моң-зарыңны тирән яшер...» . . . . . . . . . . . . . 57
Таңнарыңны каршыла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Нигә икән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Җиңүләрдән башка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Бер яфрак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Күгәрчен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
«Шыгыр-шыгыр ашыкмыйча . . . . . . . . . . . . . . . 61
Күңел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
«Бу – дөнья, шушы дөньяга...» . . . . . . . . . . . . 63
Иртә килсен язлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

Чакыр мине . *Рәфис Мөхәммәтдин*

Үзем турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Үзем булып калам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Юк, әйталмам! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Татлыдан да татлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Җиңү көнендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Ышанам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
«Тәрәзәмә таш аталар...» . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Күршеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
«Елга ярсып ташса...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Елан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Таш бәгырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Ана зары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Ник туганнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
«Яралы кош килеп кунды...» . . . . . . . . . . . . . . 78

«Шакыдың, рохсәт сорадың...» . . . . . . . . . . . 78
«Коляскама килеп тотынды да...» . . . . . . . . . 79
Болында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Шигырь язам . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Хата . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Кошлар күрсәм . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
«Ага чишмә чылтыр-чылтыр...» . . . . . . . . . . 82
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Сәламлимен язны . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Еракгагы дусларга . . . . . . . . . . . . . . . 84
Аерма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
«Йөзләремә карап гаҗәпләнмә...» . . . . . . . . . 86
Үкенмәссеңме? . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
«И туган җир...» . . . . . . . . . . . . . . . . 87
«Сорамыйм синнән, сорамыйм...» . . . . . . . . . 88
Туган җиргә җитми . . . . . . . . . . . . . . . 88
Иртәнге җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Шигъри хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Басуда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
«Әйдәләмәгез лә инде...» . . . . . . . . . . . . 90
Зур байлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Язны көткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Көзге таңда . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Туган җирдә калыйк . . . . . . . . . . . . . . 93
«Җирне тырный-тырный елый...» . . . . . . . . . 94
Әнкәйгә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Ялгыз калгач . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
«Күз алдымда синең бүгенгедәй...» . . . . . . . . 97
Гашыйк кызларга . . . . . . . . . . . . . . . . 98
«Коннәремнең син кояшы...» . . . . . . . . . . . 99
Учак яктым . . . . . . . . . . . . . . . . . . .100
«Тәңкә-тәңкә карлар ява...» . . . . . . . . . . .100
«Тормыш бит ул ярсыз дәрья...» . . . . . . . . .101
Килер язлар бар әле . . . . . . . . . . . . . .102
Нишләрмен? . . . . . . . . . . . . . . . . . . .102
Кыш һәм чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . .103

«Коннәрең көнлим кошлардан...» . . . . . . . . . 103
Авылым чибәренә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
«Талгын гына җилләр исә...» . . . . . . . . . . 104
«Сагышларга салып китмә...» . . . . . . . . . . 105
Кышкы кичтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Гашыйк егет җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Син мине ярат әле . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Көзнең дә бар җылы җиле . . . . . . . . . . . . 109
Кояшым бул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Түгәрәк дөнья . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Белмәдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
«Коннәр буе болыннарда...» . . . . . . . . . . . 111
Гөл үстерә минем иркәм . . . . . . . . . . . . . 111
Чәчәк бүләк итәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Берботен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Дулкын кочагында . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Рәхмәт! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114

Литературно-художественное издание

*Каусария Фиданевна Шафикова*
*Рафис Назипович Мухамматдинов*

«ПАРА ЛЕБЕДЕЙ»

Стихи

(на татарском языке)

Җаваплы мөхәррире Марис Нәзир
Рәссамы, бизәлеш мөхәррире Марсель Кәлимулла

Наборга бирелде 18.06.1995. Басарга кул куелды 10.07.1995. Кәгазь форматы 70х100 $^{1}/_{32}$ «Таймс» гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды. Тип. кәгазе N 1. Шартлы басма таб. 4. Тиражы 2000 данә. Заказ N 1643. Бәясе ирекле.

Бөтенрусия Мәгариф фондының Башкортстан «Мәгърифәт» бүлекчәсе нәшрияты. 450000, Уфа, Октябрь Революциясе урамы, 3/1, 212 бүлмә.

Башкортстан Республикасы 1 санлы Уфа шәһәр типографиясе, 450065,Уфа, Буревестник урамы,14.

Лицензия ЛБ N 25 от 16.08.91 г., выданная Минпечати РБ.



Кәүсәрия
ШАФИКОВА

*

Рәфис
МӨХӘММӘТДИН

•

# ИКЕ АККОШ